| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　с. Верхний Услон　　_______________

Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 24 декабрендәге 698 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан административ хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып, «Объектны төзүгә рөхсәт формасы һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасы турында» 24.11.2005 ел, №698 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 19.02.2011 ел, №117/пр боерыгы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 29 июнендәге 931 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
А.Д.Сагдеева
2 экз.